Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге Советы Карары

**КАРАР № 27**

21.07.2021 ел

Түбән Көек авылы

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советының 20.06.2012 ел, № 35 карары белән расланган "Түбән Көек авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә" үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законга, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Әтнә районы прокуратурасының 27.05.2021 елдагы 02-08-02-2021 номерлы протестын карап һәм тикшереп, фикер алышып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге Советының 20.06.2012 ел, №35 карары белән расланган "Түбән Көек авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә Муниципаль хезмәт турындагы" нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.4.1 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;";

1.2. 10 бүлектәге 10.1 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит дәүләт гражданлыгын туктату турында язма рәвештә хәбәр итәргә, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, бу хакта муниципаль хезмәткә Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит дәүләт гражданлыгы туктатылганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;";

1.3. 11 бүлекнең 11.1 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"7) чит ил гражданлыгы булу яисә, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;";

1.4. 26 бүлекнең 26.1 пунктының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 20 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 20.7 пунктын өстәргә:

“20.7 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы тору турында" 273-ФЗ номерлы Федераль закон максатлары өчен цифрлы валюта мөлкәт дип танылa;”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:atnya.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Галиәхмәтов Д.М.